РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 49 2018 елның 28 ноябре

**Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 37нче номерлы "Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә ия булу һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1.Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 37нче номерлы "Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә ия булу һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә ия булу һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре  һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 маддәсендәге 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүле читләштерүдән тыш, исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне сату тыела. Күрсәтелгән мөлкәткә карата шулай ук алардан файдалану хокукларын яңадан алу, алардан файдалану хокукын залогка тапшыру һәм мондый мөлкәттән файдалану хокукын теләсә кайсы хуҗалык эшчәнлегенең башка субъектларының устав капиталына кертү, мондый мөлкәтне арендалау килешүләре буенча хокукларны һәм бурычларын өченче затларга тапшыру (яңадан рәсмиләштерү), мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмалар тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субарендага тапшырудан тыш, һәм әгәр субарендага "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 маддәсендәге 1 кисәкнең 14 пунктында каралган мөлкәт бирелгән очракта, субарендага тапшыру тыела.»

2.Әлеге карарны гаммәви мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советы регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин